**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2023 елның 6 сентябре                    2852 номер

## КАРАР

**«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 1996 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2017 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы,"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы"на (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 03.02.2023елда үз көченә кергән) таянып, карар бирәм:

1) «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 1996 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

2) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Җитәкче**                    **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы*
*Башкарма комитетының 2023 елның 6 сентябрендәге*
*2852 номерлы карарына кушымта*

«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 1996 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

1) - 1.5 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"төзүче - үзенә караган җир кишәрлегендә яки башка хокук иясенең җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкару, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонт өчен проект документациясен әзерләүне тәэмин итүче (дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), "Росатом" атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, "Роскосмос" космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары яки җирле үзидарә органнары килешүләр нигезендә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән очракларда дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшырылган яки 2017 елның 29 июлендәге "Территорияләрне үстерү фонды" гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 218-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы нигезендә, килешүләр нигезендә төзүче функцияләрен тапшырылган) физик яки юридик зат Төзүче оешма шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган үз функцияләрен техник заказчыга бирергә хокуклы;

2) 1.5 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

техник заказчы - төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләрен башкару, проект документларын әзерләү, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау турында шартнамәләр төзи, күрсәтелгән эш төрләрен башкаруга биремнәр әзерли, инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыручы затларга, әлеге төр эшләрне башкару өчен кирәкле материалларны һәм документларны тапшыра, проект документациясен раслый, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу өчен кирәкле документларны-әлеге кодекста каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыручы һөнәри нигездә эш итүче физик зат Төзүче техник заказчы функцияләрен мөстәкыйль башкарырга хокуклы;

3) 1.5 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакция белән бәян итәргә:

Төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракта таләп ителми:

1) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган максатлар өчен физик затка бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү, реконструкцияләү, бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән торак йортның бакча җир кишәрлегендә, бакча йорты, хуҗалык корылмаларында төзү, реконструкцияләү;

1.1) 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп шәхси торак төзелеше объектларын төзүдән тыш, шәхси торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү;

2) капиталь төзелеш объектлары булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү;

«3) җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланудагы төзелмәләр һәм корылмалар төзү, аларны кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;»

4) капиталь төзелеш объектларының һәм (яки) аларның өлешләренең үзгәрешләре, әгәр мондый үзгәрешләр аларның ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикаларына кагылмаса һәм шәһәр төзелеше Регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан артмаса;

4.1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән әлеге Кодексның 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;

4.2) файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты яки җир асты байлыклары участокларыннан файдалану белән бәйле эшләрне башкару өчен җир асты байлыклары турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килештерелгән һәм расланган бораулау скважиналарын төзү, реконструкцияләү;

4.3) Россия Федерациясенең чит илләрдәге илчелекләрен, консуллыкларын һәм вәкиллекләрен төзү, реконструкцияләү;

4.2) 1,2 мегапаскаль яки 1,2 мегапаскальга кадәр басым астында табигый газны транспортировкалау өчен билгеләнгән объектларны төзү, реконструкцияләү;

4.5) элемтә чараларын урнаштыру өчен билгеләнгән 50 метр биеклектәге антенна терәкләр (матча һәм маяклар) урнаштыру;

5)әлеге Кодекс, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми торган башка очракларда.

4) 2.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында»гы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Башкарма комитеттагы вазифаи затның (яки Башкарма комитетның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә Республика порталындагы шәхси кабинетына (әгәр ул файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада күрсәтелгән булса) җибәрелә.

5 2.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Капиталь төзелеш объектын төзегән, реконструкцияләгән очракта мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза;
2) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турындагы килешү, гавами сервитут билгеләү турындагы карар, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән һәм, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракта, җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең кадастр планында урнашу схемасы, әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7.3 өлешендә башкача билгеләнмәгән булса, ана җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән;

3) төзелеш өчен рөхсәт язуы бирелгән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, яисә линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән көнгә кадәр, яисә территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), линияле объект төзелешенә рөхсәт биргән очракта территорияне планлаштыру проекты реквизитлары,;

3) РФ ШТК 48 статьясындагы 15 өлеше нигезендә расланган түбәндәге материаллардагы инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм түбәндәге материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган планлаштыру оешмасы схемасы, ә проект

документациясен линия объектларына карата әзерләнгән очракта территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган бүленгән полоса проекты (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш);

в) архитектура һәм конструктив карарлар, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар булган бүлекләр (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документларын әзерләү очрагында);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү кирәк булган очракта капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын да кертеп);

4) капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү гамәлгә ашырыла торган проект документациясенә экспертиза уңай бәяләмәсе, шул исәптән әлеге проект документациясендә капиталь төзелешнең башка объектларын, линия объектларын да кертеп, төзү яисә реконструкцияләү каралган булса (әлеге Кодексның 48 статьясындагы 12_1 өлешендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына карата), әгәр мондый проект документациясе әлеге Кодексның 49 статьясы нигезендә экспертиза узарга тиеш булса, әлеге Кодексның 49 статьясындагы 3_4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, әлеге Кодексның 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе;

7) рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт (әгәр төзүчегә Кодексның 40 статьясы нигезендә мондый рөхсәт бирелгән булса);

6) мондый объектны реконструкцияләгән очракта капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, күпфатирлы йортны реконструкцияләүнең 6.2 пунктында күрсәтелгән очракларыннан тыш, блокланган төзелештәге барлык йортларның да хокук ияләренең бер рәттә төзекләндерелгән очракта ризалыгы;

8) күпфатирлы йортта биналарның һәм машина-урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышы карары, күпфатирлы йортны үзгәртеп корганда, торак законнары нигезендә кабул ителгән яки, әгәр мондый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми милек күләме киметелсә, күпфатирлы йортта биналарның һәм машина-урыннарның барлык милекчеләренең ризалыгы;

к) проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затны аккредитацияләү турында язманың уникаль номеры, проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертиза уздыру хокукына аккредитацияләнгән юридик затларның дәүләт реестрында һәм (яисә) проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертиза нәтиҗәләре турында мәгълүмат биргән очракта;

10) мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкарганда мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык характеристикалары һәм куркынычсызлыгы характеристикасы кагылса, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар;

11) капиталь төзелеш объекты төзелеп, Россия Федерациясе законнары нигезендә аны урнаштыру белән бәйле территорияне куллануның аерым шартлары булган зона булдырылырга тиеш булган очракта, яки капиталь төзелеш объекты реконструкцияләнеп, реконструкцияләнгән объектка карата территорияне куллануның аерым шартлары булган зона булдырылырга тиеш булган яки территорияне куллануның аерым шартлары булган булдырылган зона үзгәртелергә тиеш булган очракта, территорияне куллануның аерым шартлары булган зонаны булдыру яки үзгәртү турында карар күчермәсе;

9) территорияне үстерү турында килешүнең күчермәсе, әгәр капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүне җирле үзидарә органы территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул иткән территория чикләрендә башкару планлаштырыла икән (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яки муниципаль берәмлек тарафыннан территорияне комплекслы үстерү яки мондый карарны Россия Федерациясенең әлеге кодексына яки Россия Федерациясе субъектына ярашлы билгеләнгән юридик зат тарафыннан гамәлгә ашыру турында карарны мөстәкыйль гамәлгә ашыру очракларыннан тыш).